| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
|---|---|---|
| СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

23 октябрь 2024 ел № 24

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 2021 елның 08 нче ноябрендә 32 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 ел, №289-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел № 32 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.4.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248 - ФЗ Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.2. 4.9.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел".

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан вакытыннан үз көченә керә.

Саба шәһәр җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов